# КАРАР

**2021 елның 24 ноябре** **№ 1**

**Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлегенең Югары Шөн авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәсе турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 24 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне раславрга: «I төркем инвалидлары, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылар һәм студентлар (курсантлар), 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлегенең Югары Шөн авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2022 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Югары Шөн авылында Чапаев, Октябрь, Май, урамнарында вак таш җәеп, юллар төзү һәм ремонтлау; проект-смета документациясе һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Югары Шөн авылында юлларны җәен һәм кышын карап тоту һәм чистарту;
- Югары Шөн авылында урам яктырткычларын ремонтлау һәм сатып алу;
- Югары Шөн авылында спорт мәйданчыгын төзекләндерү һәм җиһазлар сатып алу: проект-смета документлары;
- Югары Шөн авылында Октябрь урамына янгын гидрантлары, янгын краннары сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары;
- Югары Шөн авылы зираты коймасын ремонтлау, проект-смета документлары;
- Югары Шөн авылында су башнясын һәм суүткәргечне карап тоту?

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 207 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 110.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашкан 110 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлеге Югары Шөн авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «I төркем инвалидлары, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылар һәм студентлар (курсантлар), 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлегенең Югары Шөн авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2022 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны

түбәндәге эшләрне башкару буенча жирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Югары Шөн авылында Чапаев, Октябрь, Май, урамнарында вак таш җәеп, юллар төзү һәм ремонтлау; проект-смета документациясе һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Югары Шөн авылында юлларны җәен һәм кышын карап тоту һәм чистарту;
- Югары Шөн авылында урам яктырткычларын ремонтлау һәм сатып алу;
- Югары Шөн авылында спорт мәйданчыгын төзекләндерү һәм җиһазлар сатып алу: проект-смета документлары;
- Югары Шөн авылында Октябрь урамына янгын гидрантлары, янгын краннары сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары;
- Югары Шөн авылы зираты коймасын ремонтлау, проект-смета документлары;
- Югары Шөн авылында су башнясын һәм суүткәргечне карап тоту?

«РИЗА» «КАРШЫ»

- кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыеннын нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Рәислек итүче,
Важашур авыл жирлеге башлыгы П.Л. Иванов